Татарстан Республикасы
Кукмара муниципаль районының
Сәрдекбаш авыл җирлеге Советы

Карар

2021 елның 23нче ноябре №30

1. Кукмара муниципаль районы Сәрдекбаш авыл җирлеге Советының 2016 елның 16 декабрендәге 38 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Сәрдекбаш авыл җирлеге территориясендә каты коммуналь калдыкларны җыю, чыгару, ташу һәм урнаштыру Тәртибен үзгәреш кертү турында

Кукмара муниципаль районы Сәрдекбаш авыл җирлеге Советының 2016 елның 16 декабрендәге 41 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Сәрдекбаш авыл җирлеге территориясендә каты коммуналь калдыкларны җыю, чыгару, ташу һәм урнаштыру Тәртибен «Җитештерү һәм куллану калдыклары турында» 1998 елның 24 июнендәге 89-ФЗ номерлы Федераль законга туры китерү максатыннан Кукмара муниципаль районы Сәрдекбаш авыл җирлеге Советы карар бирде:

1. Кукмара муниципаль районы Сәрдекбаш авыл җирлеге Советының 2016 елның 16 декабрендәге 38 номерлы карары (Сәрдекбаш авыл җирлеге Советының 2018 елның 22 июнендәге 14 номерлы карары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) белән расланган Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Сәрдекбаш авыл җирлеге территориясендә каты коммуналь калдыкларны җыю, чыгару, ташу һәм урнаштыру Тәртибенә, 1.2 пунктның 5 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итеп, үзгәреш кертергә:

«Калдыкларны транспорт белән ташу – калдыкларны Россия Федерациясе территориясе чикләрендә автомобиль, тимер юл, һава, эчке су һәм диңгез транспортында, шул исәптән шәхси эшмәкәр яисә юридик зат милкендә булган йә аларга бирелгән башка хокуклардагы җир кишәрлеге чикләреннән тыш автомобиль юллары һәм тимер юллары буйлап ташу;»

2. Әлеге карарны авыл җирлеге территориясендә урнашкан мәгълүмат стендларында, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru) урнаштырып, халыкка игълан итәргә; шулай ук «Интернет» мәгълүмат-коммуникация челтәрендә Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

Җирлек башлыгы: И.М.Нәбиев